**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2018-2019 уку елы. 4 нче сыйныф**

Максималь балл – **54**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Борын тартыкларының барысы да кулланылган мәкальне билгеләгез. (**2 балл**)

а) *Ана яхшылыгын авырсаң белерсең.*

**ә) *Баланың бармагы авыртыр, ананың йөрәге авыртыр.***

б) *Әткәй – шикәр, әнкәй – бал.*

в) *Йомырка тавыкны өйрәтми.*

2. Нечкә сузык авазлардан гына торган мәкальне билгеләгез. (**2 балл**)

а) *Батырлыкта – матурлык.*

ә) *Батыр үз халкын яклый.*

б) *Кыюлык – бәхет.*

**в) *Дөя дә бүләк, төймә дә бүләк.***

3. Мәкальдәге ябык иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Ике туган, бергә килсә, сандугачтай сайрашыр.* (Мәкаль)

а) 5;

ә) 6;

б) 7;

**в) 8.**

4. *Йо*, *йө* кушылмаларының язылышы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

**а) тамыр сүзнең беренче иҗегендә генә язылалар;**

ә) тамыр сүзнең уртасында гына язылалар;

б) тамыр сүзнең ахырында гына язылалар;

в) тамыр сүзнең беренче иҗегендә һәм уртасында язылалар.

5. Сузык аваз хәрефләренең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) 12;

**ә) 13;**

б) 24;

в) 28.

6. Сүзләрнең мәгънәсе дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Машина, телефон, телевизор, декабрь*

**а) алынма сүзләр;**

ә) искергән сүзләр;

б) синонимнар;

в) яңа сүзләр.

7. Тамырдаш сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

**а) *күз, күзлек, күзлекле*;**

ә) *бәйрәм*, *бәйсез*, *бәйге*;

б) *иген*, *игезәк*, *игелек*;

в) *төшке*, *төшлек*, *төшем*.

8. Юнәлеш килешенең сораулары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) кемгә?

ә) кемгә? нәрсәгә?

**б) кемгә? нәрсәгә? кая?**

в) кемгә? нәрсәгә? кая? кайда?

9. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең килеше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Курыкма тугыз башлы* ***еланнан****, курык икейөзле* ***адәмнән****.* (Мәкаль)

а) баш килеш;

ә) иялек килеше;

б) төшем килеше;

**в) чыгыш килеше.**

10. Мәкальдәге фигыльнең үзенчәлекләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Мәскәү бер көндә төзелмәгән.* (Мәкаль)

а) хәзерге заман хикәя фигыль, III зат берлек санда, юклыкта;

**ә) үткән заман хикәя фигыль, III зат берлек санда, юклыкта;**

б) үткән заман хикәя фигыль, II зат берлек санда, юклыкта;

в) киләчәк заман хикәя фигыль, III зат берлек санда, юклыкта.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Мәкальләрдәге төшеп калган саннарны дөрес итеп урнаштырыгыз. (**4 балл**) (*Һәр дөрес урнаштырылган сан өчен 0,5 балл)*

Ике киңәш бер булса,
Илле егет йөз була.

Алдыңа бер карасаң,

Артыңа биш кара.

Мең ишет – бер сөйлә.

**III. Теоретик бирем.**

Сузык авазлар турында белгәннәрегезне языгыз. (**12 балл**)

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Табышмакны укыгыз, җавабын языгыз. (**1 балл**)
   ***Энәләре күп, тегә белми.***
2. ***Энәләре*** сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз. (**5 балл**)
3. Үзегез яраткан берәр йорт хайваны турында 12 – 15 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. (**12 балл**)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2018-2019 уку елы. 5 нче сыйныф**

Максималь балл – **70**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Алфавит тәртибендә дөрес урнаштырылган ялгызлык исемнәре кулланылган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) *Дилбәр, Зилә, Рөстәм, Садыйкова, Әминә*;
ә) *Илшат, Камилә, Камил, Лилия, Нияз*;
б) *Гөлия, Гөлсем, Гөлчәчәк, Гөлназ, Гөлнур*;
**в) *Әмирханов, Мансуров, Мансурова, Өммегөлсем, Хатыйп*.**

2. Тел-аңкау тартыкларыннан гына торган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) [д], [т], [з], [с], [л], [н], [ң];
**ә) [ж], [ш], [җ], [ч], [р], [щ];**
б) [б], [п], [м], [w];
в) [к], [къ], [х], [ң].

3. Югары күтәрелешле сузык авазлардан гына торган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

**а) [у], [ү], [и];**
ә) [а], [ә];
б) [у], [ү], [ы], [и];
в) [о], [ө], [ы], [э].

4. Мәкальдәге ачык иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Дөрес сөйләгән ялгышмый.* (Мәкаль)

**а) 2;**

ә) 3;

б) 4;

в) 5.

5. Мәкальдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Аръяк яр һәрвакыт ямьлерәк күренә.* (Мәкаль)

**а) *аръяк, һәрвакыт, ямьлерәк*;**

ә) *аръяк, һәрвакыт*;

б) *аръяк, ямьлерәк*;

в) *һәрвакыт*.

6. ***Җете зәңгәр*** сыйфатының дәрәҗәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) гади дәрәҗә;

ә) чагыштыру дәрәҗәсендә;

**б) артыклык дәрәҗәсендә;**

в) кимлек дәрәҗәсендә.

7. Мәкальдәге фигыльнең заманы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Бер яхшы сүз мең күңелнең җәрәхәтен төзәтер.* (Мәкаль)

а) билгеле үткән заман;

ә) билгесез үткән заман;

б) билгеле киләчәк заман;

**в) билгесез киләчәк заман.**

8. Мәкальдәге калын хәрефләр белән бирелгән фигыльнең үзенчәлекләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да **сөйләмә**.* (Мәкаль)

а) хәзерге заман хикәя фигыль, II зат берлек санда, юклыкта;

ә) боерык фигыль, III зат берлек санда, юклыкта;

б) үткән заман хикәя фигыль, II зат берлек санда, юклыкта;

**в) боерык фигыль, II зат берлек санда, юклыкта.**

9. Мәкальнең хәбәре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Таш белән атканга аш белән ат.* (Мәкаль)

а) *таш*;

**ә) *ат*;**

б) *аш*;

в) *атканга*.

10. Мәкальдәге тиңдәш кисәкләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Ир-егет өйдә туар, яуда үләр.* (Мәкаль)

а) *ир-егет*;

ә*) өйдә, яуда*;

**б) *туар, үләр*;**

в) *өйдә*, *яуда*, *туар*, *үләр*.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Роберт Миңнуллинның «К»лар тулган бакчага» шигыреннән алынган юлларны үзегез дәвам итеп языгыз. (**10 балл)**

Бу бакчага ни булган?
Бакча «К» белән тулган.

*Мисал өчен:*

Карлыган һәм кәбестә,
Кишер, карбыз һәм кабак.
Крыжовник һәм кукуруз,
Кыяр, кавын, кузгалак.

*(башка вариантлар да булырга мөмкин. К хәрефеннән башланган, җиләк-җимешне, яшелчәләрне белдергән сүзләр булуы, рифма саклануы сорала)*

## III. Теоретик бирем.

Киләчәк заман хикәя фигыль турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. (**12 балл**)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Гали белән Кәҗә*
*Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,*
*Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.*
*Гали аны чирәм белән кунак итә,*
*Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.*
(Габдулла Тукай)

1. ***Гали*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. (**5 балл**)
2. ***Аны, белән, селкетә*** сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. (**6 балл**)
3. Кәҗәгә хас 10 сыйфат языгыз. (**5 балл**)

4. Кәҗә турында табышмак языгыз. (**2 балл**)

5. Шигырьнең эчтәлеген 10 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**10 балл**)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2018-2019 уку елы. 6 нчы сыйныф**

Максималь балл – **65**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге ябык иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Өй кыекларында, капкаларда, коймаларда мендәр-мендәр, күбектәй йомшак кар асылынып тора.* (Ш.Галиев)

**а) 17;**
ә) 16;
б) 15;
в) 14.

2. ***Явызлык*** сүзенә дөрес транскрипция ясалган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) [йаwозлокъ];
ә) [яwызлыкъ];
б) [йаузлыкъ];
**в) [йаwызлыкъ].**

3. Җөмләдәге сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Әнә киң яланнар, әнә уйсу болыннар, әнә зур урамнар – һәммәсе яшәреп утыралар.* (Г.Ибраһимов)

а) *һәммәсе*;
ә) *әнә*, *әнә*, *әнә*, *һәммәсе*;
**б) *әнә, әнә, әнә, һәммәсе, утыралар*;**
в) *әнә*, *әнә*, *әнә*, *һәммәсе*, *яшәреп*, *утыралар*.

4. Сүзнең язылышы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

**а) *мәгълүмат*;**
ә) *мәгълумат*;
б) *магълүмат*;
в) *мәгълүмәт*.

5. Җөмләдәге фразеологизмның мәгънәсе дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Укый торган китабын куеп, Гөлшәһидә төнге авазларга колак салды.* (Г.Әпсәләмов)

а) игътибар итте;
**ә) тыңлады;**
б) колагын каплады;
в) игътибар итмәде.

*6. Матай*, *лимон*, *попса*, *сәпит* кебек сүзләрнең кайсы төркемгә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) терминнар;
**ә) жаргоннар;**
б) һөнәрчелек сүзләре;
в) тарихи сүзләр.

7. Ясалма исемнәрдән генә торган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) *бишек*, *тишек*, *тизлек*, *урманлык*;
ә) *РТ*, *бала-чага*, *бармак*, *көмеш*;
**б) *ир-егет*, *ашъяулык*, *үги ана яфрагы*, *авылдаш*;**
в) *күзлек*, *тимерче*, *баллы*, *татарча*.

8. Мәкальдәге калын хәрефләр белән бирелгән фигыльнең үзенчәлекләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Оясын* ***актарсаң****, агусыз елан да тешләр.* (Мәкаль)

а) үткән заман хикәя фигыль, II зат берлек санда, барлыкта;
ә) боерык фигыль, II зат берлек санда, барлыкта;
б) шарт фигыль, II зат күплек санда, барлыкта;
**в) шарт фигыль, II зат берлек санда, барлыкта.**

9. Иярчен кисәкләре булган мәкальне билгеләгез. (**2 балл**)

а) *Урман – авыз, кыр – колак, күл – күз.*
ә) *Кыюлык – бәхет.*
б) *Ата – беләк, ана – йөрәк.*
**в) *Әнкәм йорты – алтын бишек.***

10. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Ай-яй, җәелеп тә караган Идел!* (Г.Ахунов)

а) хикәя;
ә) боерык;
**б) тойгылы хикәя;**
в) тойгылы боерык.

**II. Башыгызны эшләтегез.**

*Һәр кеше исеменә 0,5 балл.* (**10 балл**)

**III. Теоретик бирем.**

Метафора турында белгәннәрегезне языгыз, фикерегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. Образлылыкларын югалткан, образлы һәм индивидуаль-стилистик метафоралар бер-берсеннән ничек аерыла? (**12 балл**)

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

*Кулыңнан бер яхшылык килсә, бишне кыл.* (Мәкаль)

1. ***Яхшылык*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. (**5 балл**)
2. ***Биш*** сүзе кулланылган 6 фразеологизм уйлап языгыз. (**3 балл**)
3. ***Кулыңнан*** сүзенә морфологик анализ ясагыз. (**3 балл**)
4. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2018-2019 уку елы. 7 нче сыйныф**

Максималь балл – **79**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Гөлназ, төлке, телефон, канәгать, өстәл, дөнья.*

а) ике сүз;

**ә) өч сүз;**

б) дүрт сүз;

в) биш сүз.

2. Җөмләләрдәге сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Көч һәм батырлык яуда гына кирәк дигән кешеләр бик нык ялгышалар. Тып-тыныч тормыш та кешедән гел батырлык сорый. Кайчагында кешегә, дөреслекне әйтер өчен дә, зур батырлык кирәк.* (Ф.Яруллин)

а) *кайчагында*;

ә) *тып-тыныч*, *кайчагында*;

**б) *ялгышалар, тып-тыныч, кайчагында*;**

в) *ялгышалар*, *тып-тыныч*, *кайчагында*, *сорый*.

3. Җөмләдәге ТСТ калыбындагы иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Йорт биеклегендәге алмагачларны күргәч, мин ах иттем, бер ботактан алма өзеп алганымны сизми дә калдым...* (Г.Гыйльманов)

а) 12;
ә) 14;
б) 15;
**в) 16.**

4. Җөмләдәге алынма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Чәй эчеп утыра торгач, әби шунда җир, туфрак турында сүз башлады да шкаф эченнән майонез банкасы алып килде.* (М.Мәһдиев)

а) *майонез, банкасы*;
ә) *шкаф*;
б) *шкаф, майонез, банкасы*;
**в) *чәй, шкаф, майонез, банкасы.***

5. Урта диалект үзенчәлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

**а) [й] авазы урынына [җ] әйтү;**
ә) яңгырау тартыкларның саңгыраулашуы;
б) [къ], [гъ] урынына [к], [г] әйтү;
в) иренләшмәгән [а] авазын куллану.

6. Җөмләдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Сикерә-сикерә, ашкына-ашкына, уйный-уйный, җырлый-җырлый, гөрли-гөрли гөрләвекләр ага, улым!* (Г.Мөхәммәтшин)

а) *сикерә-сикерә, ашкына-ашкына, уйный-уйный, җырлый-җырлый, гөрли-гөрли*;
ә) *уйный-уйный, җырлый-җырлый, гөрли-гөрли*;
**б) *уйный-уйный, җырлый-җырлый, гөрли-гөрли, гөрләвекләр*;**
в) *уйный-уйный, җырлый-җырлый, гөрли-гөрли, гөрләвекләр, ага*.

7. Мәкальдәге фигыльләрнең төркемчәләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Уйламыйча башлама, башлаган эшне ташлама.* (Мәкаль)

**а) хәл фигыль, боерык фигыль, сыйфат фигыль, боерык фигыль;**
ә) хәл фигыль, боерык фигыль, хикәя фигыль, боерык фигыль;
б) инфинитив, боерык фигыль, сыйфат фигыль, боерык фигыль;
в) хикәя фигыль, боерык фигыль, сыйфат фигыль, боерык фигыль.

8. Шигъри юлларда кулланылмаган сыйфат дәрәҗәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Яшел бөре тәрәз алдымда,*
*кисәк-кисәк зәп-зәңгәр күк,*
*алтынсу нур,*

*чем-кара сыерчык ботакта.* (Р.Фәйзуллин)

а) гади;

**ә) чагыштыру;**

б) артыклык;

в) кимлек.

9. Сүзләр арасында тезүле бәйләнеш кулланылган мәкальне билгеләгез. (**2 балл**)

а) *Урлап ашамаса, кәҗәнең тамагы туймый.*

ә) *Җилгә каршы төкермә, битеңә төшәр.*

б) *Тамчыдан күл җыела.*

**в) *Эт батырга өрер, куркакны тешләр.***

10. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Сез моны һәрвакыт исегездә тотыгыз!* (Г.Хәсәнов)

**а) боерык;**

ә) хикәя;

б) тойгылы боерык;

в) тойгылы хикәя.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Бирелгән мәкальләрнең мәгънәләрен аңлатып языгыз. Һәр мәкальгә 5-6 җөмлә. (**15 балл**) *( Дөрес, хатасыз язылган һәр аңлатма өчен 5 балл.*
*Һәр грамматик, пунктуацион, стиль хатасы өчен 0,5 балл киметелә.)*

1. *Сүзне әйтмә, әйтсәң – кайтма.*
2. *Кар башына кар җитәр.*
3. *Кул ярасы бетәр,*

*Тел ярасы бетмәс.*

## III. Теоретик бирем.

Тамыр һәм ясалма сыйфатлар турында белгәннәрегезне языгыз, фикерегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. (**12 балл**)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Кешегә яманлык теләгәнче, үзеңә яхшылык тelə.* (Мәкаль)

1. ***Үзеңә*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. (**5 балл**)
2. ***Кеше*** сүзенең синонимнарын языгыз. (**3 балл**)
3. Мәкальдәге барлык сүзләргә дә морфологик анализ ясагыз. (**12 балл**)

4. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2018-2019 уку елы. 8 нче сыйныф**

Максималь балл – **69**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Татар алфавитындагы 11 нче хәреф дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Җ;
ә) Й;
**б) З;**
в) К.

2. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Мин монда барыгыздан да өлкән, бөтенегездән дә күбрәк күргән, бик борынгы серләрне сөйләргә кодрәтем җитә, дигән кебек, картларча тыныч-салмак кына агып яткан Идел – үзе бер тамаша.* (Л.Ихсанова)

а) 1;
**ә) 2;**
б) 3;
в) 4.

3. ***Унбиш*, *төнге*, *болыт*** сүзләренең язылыш принцибы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) фонетик;
**ә) морфологик;**
б) график;
в) тарихи-традицион.

4. Шигъри юллардагы омонимнарның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Малай йөгерә*
*Өенә табан,*
*Ялтырый табан.* (Н.Гайсин)
а) саф лексик;
ә) омофоннар;

б) омографлар;
**в) омоформалар.**

5. Фразеологик әйтелмәнең синонимы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

***Баштан сыйпамау***
а) *хафага төшү*;
**ә) *рәхмәт әйтмәү*;**
б) *күрмәгәнне күрсәтү*;
в) *теңкәгә тию*.

6. Исем ясагыч кушымчалардан гына торган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) *-ын/-ен, -лай/-ләй, -ча/-чә*;
**ә) *-чы/-че, -ыч/-еч, -кыч/-кеч*;**
б) *-әс/-әч, -чан/-чән, -чыл/-чел*;
в) *-ар/-әр, -ай/-әй, -а/-ә*.

7. Мәкальдә кулланылган сүз төркемнәре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Какшаган көпчәккә ышанып юлга чыкма.* (Мәкаль)
**а) сыйфат фигыль, исем, хәл фигыль, исем, боерык фигыль;**
ә) хикәя фигыль, исем, хәл фигыль, исем, боерык фигыль;
б) сыйфат, исем, хәл фигыль, исем, боерык фигыль;
в) сыйфат фигыль, исем, хәл фигыль, исем, инфинитив.

8. Сүзтезмәнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

***Шулчак кайту*** –
а) рәвешле фигыль сүзтезмә;
**ә) алмашлыклы фигыль сүзтезмә;**
б) фигыльле алмашлык сүзтезмә;
в) алмашлыклы исем сүзтезмә.

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Вил хәзер һәркөн, **дәрестән соң**, кошлар ашата.* (Ә.Давыдов)
а) тәмамлык;
ә) вакыт хәле;
б) урын хәле;
**в) аныклагыч.**

10. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*Моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.* (Г.Тукай)
**а) җыйнак, хикәя;**
ә) җыйнак, хикәя, тойгылы;

б) җәенке, хикәя;

в) кушма.

**II. Башыгызны эшләтегез.**

Бирелгән җөмләләрдән фразеологик сүзтезмәләрне табыгыз. Аларны бер сүз (сүзтезмә) белән алыштырып языгыз. (**6 балл**)

Кызы вакытында кайта алырмы дип борчыла әнисе. Фарук әрәмтамак (эшлексез) түгел. Сания бу юлы аның ялагайлануына артык игътибар итмәде (бирешмәде). Их, аның [Садыйкның] урысчасы, укымышы тагын да көчлерәк булса, ул зур эшләр башкарыр иде. Ә ул әйткәнен үти инде.

**III. Теоретик бирем.**

Сәбәп һәм максат хәлләре, аларның үзенчәлекләре турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. (**12 балл**)

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

*Һавадагы торнаны тотам дип, кулыңдагы чыпчыкны ычкындырма* (Мәкаль)

1. Төшеп калган хәрефләрне өстәп, мәкальне күчереп языгыз. (**2 балл**)
2. ***Һавадагы*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. (**5 балл**)
3. ***Һавадагы***, ***тотам***, ***дип*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (**6 балл**)
4. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә языгыз. Тыныш билгеләренең куелышын кагыйдәләргә таянып аңлатыгыз. (**6 балл**)
5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2018-2019 уку елы. 9 нчы сыйныф**

Максималь балл – **69**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләләрдәге сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Язмыш синең тез астыңа китереп сукса, егылмас өчен, якасынаябыш. Утларга салса, үзең аннан да көчле ян, шулвакыт аның кызуын сизмәссең.* (Ф.Яруллин)

а) *ябыш*;

ә) *ябыш, шулвакыт*;

б) *егылмас,ябыш, шулвакыт*;

**в) *егылмас, ябыш, шулвакыт, сизмәссең.***

2. Җөмләдәге ТСТ калыбындагы иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Мин көтәм, менә ул канатларын җыяр да, иптәшләре кебек үк, җиргә囲 таштай атылып төшәр.* (**И.Гази**)

а) 11;

**ә) 12;**

б) 13;

в) 14.

3. Мәкальдәге антонимнар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Атаң-анаң – чын дустың, дус-ишләрең – юлдашың.* (Мәкаль)

**а) *атаң-анаң*;**

ә) *дус-ишләрең*;

б) *атаң-анаң, дус-ишләрең*;

в) *дустың, юлдашың*.

4. Шигъри юллардагы калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Курыкмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын;*
*Мин тимәм сезгә,* ***фәкать*** *сайравыгызны тыңлармын.* (Г.Тукай)

**а) актив;**

ә) тарихи;

б) архаизм;

в) неологизм.

5. Җөмләдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Аның киемнәре элеккечә пөхтә, ап-ак күлмәгенә кара галстук таккан, чалбары яхшылап үтүкләнгән, туфлиләре ялтырап тора.* (Ф.Садриев)

**а) *киемнәре, элеккечә, яхшылап, үтүкләнгән, ялтырап*;**

ә) *киемнәре, элеккечә, яхшылап, үтүкләнгән*;

б) *киемнәре, элеккечә, ап-ак, яхшылап, үтүкләнгән, ялтырап*;

в) *киемнәре, күлмәгенә, кара, үтүкләнгән, ялтырап*.

6. Мәкальдә кулланылган сүз төркемнәре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Дөньяда ата-анадан башка бар да табыла.* (Мәкаль)

а) исем, исем, бәйлек сүз, билгеләү алмашлыгы, теркәгеч, хикәя фигыль;

ә) исем, исем, бәйлек, билгеләү алмашлыгы, кисәкчә, хикәя фигыль;

**б) исем, исем, бәйлек сүз, билгеләү алмашлыгы, кисәкчә, хикәя фигыль.**

в) исем, исем, бәйлек сүз, хәбәрлек сүз, кисәкчә, хикәя фигыль;

7. Җөмләдәге санның мәгънә төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ярты ел йомгакларыннан күренгәнчә, сез туксан тугыз бөтен уннан бер процент өлгереш биргәнсез.* (Т.Миңнуллин)

**а) микъдар;**

ә) бүлем;

б) чама;

в) җыю.

8. Җөмләдәге ияләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Елга төбен үги ана яфрагы, бака яфрагы, каз үләне баса.* (Р.Төхфәтуллин)

а) *яфрагы*, *яфрагы*, *үләне*;

ә) *үги ана яфрагы*, *бака яфрагы*, *үләне*;

**б) *үги ана яфрагы, бака яфрагы, каз үләне*;**

в) *елга*, *үги ана яфрагы*, *бака яфрагы*, *каз үләне*.

9. Иярчен җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Юлда йоклаганда, бер күзең ачык булсын.* (Мәкаль)

а) синтетик иярчен шарт җөмлә;

ә) синтетик иярчен урын җөмлә;

б) аналитик иярчен вакыт җөмлә;

**в) синтетик иярчен вакыт җөмлә.**

10. Кушма җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Галимҗан Ибраһимов үзе төзегән, үзе барлыкка китергән дәреслекләр нигезендә укыта*. (С.Кудаш)

**а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;**

ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

б) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

в) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Җөмләләрдә кулланылган ***тума*** сүзенең мәгънәләрен аңлатып языгыз. **(5 балл)**

*Ул сыерның кайдан чыкканлыгын, аның кем тумасы булганлыгын сөйли – **токым**.*

*Тума ага – **бертуган**.*

*Авыл тумасына шәһәр һавасы килешмәс булды. – **теге яки бу урында туып-үскән, шуннан чыккан кеше**.*

*Эт белән бүре туган булса да, тума дошман. – **тумыштан***

*Сабир тума надан, ләкин шат, шаян бер кызга өйләнә. – **бөтенләй, тулысынча.***

## III. Теоретик бирем.

Татар орфографиясенең принциплары турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. (**12 балл**)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Аккош очар күл күреп, былбыл очар гөл күреп.* (Мәкаль)

1. ***Күреп*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. (**5 балл**)
2. ***Былбыл*** сүзенең синонимын языгыз. (**1 балл**)
3. ***Аккош, очар, күреп*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (**6 балл**)
4. Җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. Тыныш билгеләренең куелышын кагыйдәләргә таянып аңлатыгыз. (**8 балл**)
5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)

# Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2018-2019 уку елы. 10 нчы сыйныф

Максималь балл – **76**

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Татар алфавитындагы 20 нче урында урнашкан хәреф дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) П;

ә) О;

**б) Ө;**

в) У.

2. ***Тукран*** сүзнең транскрипциясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) [тукран];

ә) [тукъран];

б) [тукыран];

**в) [тукъыран].**

3. Шигъри юллардагы омонимнарның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Эчәрмен әле сусатса –*
*Алсу татлы*
*Су сатса.* (Р.Миңнуллин)

а) саф лексик омонимнар;

**ә) омофоннар;**

б) омографлар;

в) омоформалар.

4. Фразеологик әйтелмәнең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

***Бака туе ясау***

**а) кешеләрнең бер-берсен тыңламыйча, барысы бергә кычкырып сөйләшүләре;**

ә) бик күп кешенең бер мәҗлестә матур итеп күңел ачулары;

б) бака кебек юан, билсез кешеләрнең бергә җыелып сөйләшүләре;

в) бик матур үткәрелгән туй мәҗлесе.

5. Ясагыч кушымчасы булган сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

а) *салкыннар, китапханә, кызгылт*;

ә) *өстәлдә, укысаң, көлеп*;

**б) *битлек, хәбәрләш, җырлап*;**

в) *зәңгәрсу, балык, киттеләр*.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Бу дөньяга без килгәнбез икән*
***Юкка*** *түгел,* ***юкка*** *түгелдер.* (Н.Нәҗми)

а) юнәлеш килешендәге исем;

**ә) сәбәп-максат рәвеше;**

б) хәбәрлек сүз;

в) исемләшкән хәбәрлек сүз.

7. Җөмләдәге сүз төркемнәре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Атымны учак яктысына китереп бәйләдем дә мин дә малайлар арасына чүгәләдем.* (Г.Бәширов)

а) исем, исем, бәйлек сүз, хәл фигыль, хикәя фигыль, теркәгеч, алмашлык, кисәкчә, исем, бәйлек сүз, хикәя фигыль;

ә) исем, исем, исем, хәл фигыль, хикәя фигыль, кисәкчә, алмашлык, кисәкчә, исем, бәйлек сүз, хикәя фигыль;

б) исем, исем, исем, хәл фигыль, хикәя фигыль, теркәгеч, алмашлык, теркәгеч, исем, бәйлек сүз, хикәя фигыль;

**в) исем, исем, исем, хәл фигыль, хикәя фигыль, теркәгеч, алмашлык, кисәкчә, исем, бәйлек сүз, хикәя фигыль.**

8. Җөмләдәге куелырга тиешле тыныш билгеләренең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Кечкенә генә куыш ясалып беткәч Иван Иванович шунда тынычлап ял итте һәм төнге ябалаклар тавышы булмаса ул әле бәлки кояш чыкканга кадәр дә кузгалмый ятар иде* (А.Расих)

**а) 7;**

ә) 6;

б) 5;

в) 4.

9. Иярчен җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Рөстәмнең күзләре дүрт булды: ул берничә абагада нәфис бриллиант кашларыдай җем-җем итеп торган чәчәкләр күрде.* (Г.Кутуй)

а) иярчен хәбәр җөмлә;

ә) иярчен рәвеш җөмлә;

**б) иярчен сәбәп җөмлә;**

в) иярчен күләм җөмлә.

10. Кушма җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Март ахыры якынлашкач, беренче яңалык шул булды: кычыткан күбәләге оча башлады.* (Г.Хәсәнов)

а) тиңдәш ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

**ә) тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;**

б) бер-бер артлы ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

в) берничә төр ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Әлеге аутентик сөйләш үрнәген әдәби телгә әйләндереп языгыз. **(10 балл)** *Һәр хата өчен 0,5 балл киметелә.*

*Начар вакытлар булды. Әти, әни булды, әлбәттә, 8 бала үстек. Сугыштан соңгы чорлар. Әти кычыткан алып кайта, әни аны зур табакка салып, бер стакан он сибеп бирә иде. Бер табактан ашый идек. Шуннан соң кул белән җир казыйбыз, күршеләр белән алмашлап. Колхозга эшкә йөрибез...*

*Сабантуйлар була иде. Колгага яулык бәйләп, кемдә нәрсә бар, шуны җыеп йөри торганнар иде.*

### III. Теоретик бирем.

Алмашлык сүз төркеме турында белгәннәрегезне языгыз, фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. (**12 балл**)

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Ялгыз агачны җил бора, күп агач җилне бора.* (Мәкаль)

1. ***Ялгыз*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. (**5 балл**)
2. ***Агач*** тамырыннан яңа 6 сүз ясагыз. Аларның кайсы сүз төркеменә караганлыкларын күрсәтегез. (**3 балл**)
3. ***Ялгыз, күп, бора*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (**6 балл**)
4. Җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. Тыныш билгеләренең куелышын кагыйдәләргә таянып аңлатыгыз. (**8 балл**)
5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)

## Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2018-2019 уку елы. 11 нче сыйныф

Максималь балл – **75**

### I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Яшь керпеләр йомгакланып төрелергә һәм сүтелергә өйрәнделәр.* (М.Рафиков)

а) *яшь*, *йомгакланып*, *төрелергә*, *сүтелергә*, *өйрәнделәр*;
ә) *йомгакланып*, *төрелергә*, *сүтелергә*, *өйрәнделәр*;
б) *йомгакланып*, *төрелергә*, *өйрәнделәр*;
**в) *төрелергә*.**

2. Җөмләдәге сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Дөядәй алтының булганчы, төймәдәй акылың булсын.* (Мәкаль)

а) *дөядәй, төймәдәй*;
**ә) *дөядәй, төймәдәй, булганчы*;**

б) *булганчы*;

в) *булганчы*, *булсын*.

3. Җөмләдәге калын хәрефләр белән күрсәтелгән фразеологизмның мәгънәсе дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Син әбиеңнең сүзен* ***колагыңа да элмисең икән****.* (Г.Мөхәммәтшин)

а) кушкан эшне эшләмәү;

**ә) әйткәнне бөтенләй тыңламау;**

б) ишетсә дә, юри ишетмәмешкә салыну;

в) сер сакламау.

4. Җөмләдәге алынма сүзләрнең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Каен суының шифалы булуы бик табигый, чөнки аның составында виноград шикәре, төрле кислота һәм тозлар бар.* (К.Дәүләтшин)

а) 5;

ә) 6;

**б) 7;**

в) 8.

5. Җөмләдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Тургайлар җир-ана куенына гәрәбәдәй бөртекләр салучы игенчеләрне мөкатдәс хезмәткә – язгы чәчүгә чакыралар.* (К.Тәхәветдинов)

а) *җир-ана*, *игенчеләрне*, *язгы*, *чәчүгә*;

**ә) *җир-ана*, *гәрәбәдәй*, *игенчеләрне*, *язгы*, *чәчүгә*;**

б) *җир-ана*, *куенына*, *гәрәбәдәй*, *игенчеләрне*, *язгы*, *чәчүгә*;

в) *тургайлар*, *гәрәбәдәй*, *бөртекләр*, *игенчеләрне*, *язгы*, *чәчүгә*.

6. Җөмләдәге алмашлыклар һәм аларның мәгънә төркемчәләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Аларның һәммәсе дә минем өчен яңа кешеләр, шуңа күрә алар һәммәсе дә кызыксындыралар.* (С.Кудаш)

**а) *аларның* – зат алмашлыгы, *һәммәсе* – билгеләү алмашлыгы, *минем* – зат алмашлыгы, *шуңа* – күрсәтү алмашлыгы, *алар* – зат алмашлыгы, *һәммәсе* – билгеләү алмашлыгы;**

ә) *аларның* – зат алмашлыгы, *һәммәсе* – билгеләү алмашлыгы, *минем* – тартым алмашлыгы, *шуңа* – күрсәтү алмашлыгы, *алар* – зат алмашлыгы, *һәммәсе* – билгеләү алмашлыгы;

б) *аларның* – зат алмашлыгы, *һәммәсе* – билгеләү алмашлыгы, *минем* – зат алмашлыгы, *шуңа күрә* – күрсәтү алмашлыгы, *алар* – зат алмашлыгы, *һәммәсе* – билгеләү алмашлыгы;

в) *аларның* – зат алмашлыгы, *һәммәсе* – күрсәтү алмашлыгы, *минем* – зат алмашлыгы, *шуңа* – күрсәтү алмашлыгы, *алар* – зат алмашлыгы, *һәммәсе* – күрсәтү алмашлыгы.

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Атымны учак яктысына китереп бәйләдем* ***дә*** *мин дә малайлар арасына чүгәләдем.* (Г.Бәширов)

а) урын-вакыт килеше кушымчасы;

ә) кисәкчә;

**б) теркәгеч;**

в) бәйлек.

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Адәм балаларына дөньяда төрле авырлыкларга түзәргә туры килә.* (Ф.Агиев)

а) ике составлы, ким;

ә) гомум үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә, ким;

**б) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә, тулы;**

в) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә, ким.

9. Иярчен җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Һәркемгә билгеле: сәламәтлек – тормышның яме, чибәрлекнең нигезе.* (Ш.Сайкин)

**а) иярчен ия җөмлә;**

ә) иярчен хәбәр җөмлә;

б) иярчен тәмамлык җөмлә;

в) иярчен аергыч җөмлә.

10. Кушма җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (**2 балл**)

*Әллә инде соңгы кеше булып төшкәнгә, әллә нәкъ менә шул зур чемоданы булганга, бу кыз башкалардан бик аерылып тора иде.* (Н.Акмалов)

а) бер-бер артлы ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

**ә) тиңдәш ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;**

б) тиңдәш түгел ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

в) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Оренбург өлкәсенә караган әлеге сөйләш үрнәге белән танышыгыз. Түбәндә бирелгән туганлык атамаларының әдәби телдәге вариантын языгыз. **(7 балл)**

*биана – кайнана*
*йанагай – каенэне*
*қайын сеңлесе – каенсеңел*
*апай – апа*

*балдыс – балдыз*
*җеңгәй – җиңги*
*биатай – кайнатай*

## III. Теоретик бирем.

Тамыр һәм ясалма исемнәр турында белгәннәрегезне языгыз, фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. (**12 балл**)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Күз әйткән: “Уңдырам”, – дип, ә яз әйткән: “Тукта әле, мин нәрсә әйтермен”, – дип.* (Мәкаль)

1. ***Уңдырам*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. (**5 балл**)
2. ***Яз*** тамырыннан 6 яңа сүз ясагыз. (**3 балл**)
3. ***Әйткән***, ***тукта***, ***әле***, ***нәрсә*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (**8 балл**)
4. Җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. Тыныш билгеләренең куелышын кагыйдәләргә таянып аңлатыгыз. (**8 балл**)
5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)